Татар мәктәбендә укучы балаларга татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр
6 нчы сыйныф 2016-2017 уку елы

**Максималь балл – *44*** *Үткәрү вакыты- 60 минут*

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1.***Китап, урман, җәйге, язгы, укыйлар, кәгазь, унбиш*** сүзләре арасыннан ничә сүз сингармонизм законына буйсынмаган? ***(2 балл)***

а) ике сүз; ә) өч сүз; б) дүрт сүз; в) биш сүз.

2.Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзләр санын билгеләгез. ***(2 балл)***

*Кошлар ишегалды өстеннән бер әйләнеп үттеләр дә, тезелешеп, көзге кояшка таба юл тоттылар.*(Л.Зөлкарнәй)

а) 2; ә) 3; б) 4; в) 5.

3.***Көмешсу, җанкай, тозсыз*** сүзләренең транскрипциясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) [көмөшсу], [җаӊкай], [тоссыс];
ә) [көмөшсу],[җамкай], [тоссоз];
б) [көмөшсу],[җанкай], [тозсоз];
в) [көмөшсу], [җаӊкай], [тоссос].

4.Җөмләдә кулланылган күчерелмә мәгънәдәгесүзне билгеләгез. ***(2 балл)***

*Җәйге көн әкренләп сүнде, ниһаять, төн булды.* (Ә.Еники)

а) җәйге; ә) көн; б) сүнде; в) төн.

5. Архаизмнардан торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) ихата, йиләк, куцат, шартлама;
ә) угры, вә, гыйлем, еглау;
б) морза, патша, алпавыт, шишәк;
в) кәбестә, түтәл, маңгай, авылдаш.

6.Калын хәрефләр белән бирелгән исемнәрнең үзенчәлекләрен билгеләгез. ***(2 балл)***

***Башың*** *эшләмәсә,* ***аягың*** *күп йөрер.* (Мәкаль)

а) төшем килешендә, тартым белән төрләнгән;
ә) төшем килешендә, тартым белән төрләнмәгән;
б) иялек килешендә, тартым белән төрләнгән;
в) баш килештә, тартым белән төрләнгән.

7.Сан ияреп килгән сүзнең атамасын билгеләгез. ***(2 балл)***

а) сыйфатланмыш; ә) саналмыш; б) исем; в) сыйфат.

8.Саннардан гына торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) ике, унау, өчтән бер, алтмыш тугыз;
ә) алтынчы, бер-ике, акыл, песи;
б) унике, сиксән, меңнәрчә, күп;
в) егерме сигез, кырык, аз, илле.

9.Фигыльнең юклык төрен белдерә торган кушымчалар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) -ма/-мә; ә) -мый/-ми; б) -ма/-мә, -мый/-ми; в)-ма/-мә,-мы/-ме, -мый/-ми.

10.Фигыльләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) мин, өстәл, ике, бардым;
ә) уңда, беркем, кайда, кайтты;
б) ашый, кайт, укыса, карады;
в) үземнеке, карт, тигез, йөгерер.

11.Тиңдәш тәмамлыклар кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Әлфиянең әнисе белемле, чибәр һәм яхшы күңелле.
ә) Инсаф кыш көне чаңгы шуа, тимераякта йөри.
б) Сөмбел әнисе белән кибеткә бара.
в) Мин авылдагы дәү әтием белән дәү әниемне бик сагындым.

12.Җөмләнең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Сөйләгез, агачлар, сөйләгез!* (М.Мәһдиев)

а) хикәя; ә) боерык; б) тойгылы; в) сорау.

**II. Теоретик бирем.**

Сыйфат сүз төркеме турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. ***(10 балл)***

**III. Иҗади бирем.**

Сүзләргә сузык авазлар өстәп, мәкальне языгыз.Мәкальдәге сүзләрнең кайсы сүз төркеменә карагаанлыгын билгеләгез. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(10 балл)***

ДНЬЙД Ң ЗР БЛК – БЛМ.